ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИКИФОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ НИКИФОРОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул.Карла Маркса, д.2, с. Никифорово,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422166

Карл Маркс ур., 2 нче йорт, Никифорово авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422166

тел.(факс): (85563) 2-42-38; e-mail: Nikifor.Mam@tatar.ru, www:mamaduysh.tatarstan.ru

---

Постановление — Карар

“31” октябрь 2024 ел. — № 11

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлегенең су белән тәэмин итү һәм су агызу схемасын раслау турында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында» 07.12.2011 ел, № 416-ФЗ Федераль кануны, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү схемалары турында» 05.09.2013 ел, № 782 РФ Хөкүмәте Карары, « Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль кануны, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Никифорово авыл җирлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлегенең су белән тәэмин итү су агызу схемасын расларга.
2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеген су белән тәэмин итү һәм су агызу схемасын раслау турында» 2015 елның 25 декабрендәге 20 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге арарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка игълан ителгәннән (басылып чыкканнан) соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Никифорово авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе: С.Н.Степанов